ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урынга күчерү, аларны саклау, кире кайтару, күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны түләү тәртибе турында” 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны” сүзләрен “һәм күчерү, саклау бәясен” сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда “күчергән һәм саклаган өчен чыгымнарны” сүзләрен “һәм күчерү, саклау бәясен” сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) транспорт чарасы – двигателенең эшләү күләме 50 куб сантиметрдан артык булган яисә электр двигателенең максималь куәте 4 киловаттан артык булган һәм максималь конструктив тизлеге сәгатенә 50 километрдан артык булган автомототранспорт чарасы, шулай ук аның дәүләт теркәве узарга тиешле прицеплары, кечкенә суднолар, тракторлар, үзйөрешле юл-төзелеш машиналары һәм башка үзйөрешле машиналар, йөртү өчен юл хәрәкәте иминлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә махсус хокук бирелә торган транспорт чаралары, аларның дәүләт теркәве узарга тиешле прицеплары;”;

4) 3 статьяның 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Машина йөртүче үзе булмаганда, беркетмә ике пунәтәй катнашында йә видеоязма кулланып төзелә. Машина йөртүче үзе булмаганда төзелгән беркетмәнең күчермәсе тоткарланган транспорт чарасын кире кайтару турында вазыйфаи зат карары белән бергә аның хуҗасына, хуҗасы вәкиленә яисә әлеге транспорт чарасын йөртү өчен кирәкле документлары булган затка транспорт чарасын тоткарлау сәбәбе бетерелгәннән соң кичекмәстән бирелә.”;

5) 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4 статья. **Транспорт чарасын аның хуҗасы яисә тоткарланган транспорт чарасыннан файдалану йә аның белән эш итү хокукына ия зат булмаганда тоткарлау турында мәгълүмат бирү**

Транспорт чарасын аның хуҗасы яисә тоткарланган транспорт чарасыннан файдалану йә аның белән эш итү хокукына ия зат булмаганда тоткарлау турында мәгълүмат бирү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

6) 5 статьяның 5 өлешендә “ике пунәтәй барында” сүзләреннән соң “йә видеоязма кулланып” сүзләрен өстәргә;

7) 7 статьяның 2 өлешендә “бирү” сүзен “кире кайтару” сүзләренә алмаштырырга;

8) 8 статьяда:

а) исемендә “бирү” сүзен “кире кайтару” сүзләренә алмаштырырга;

б) “бирү” сүзен “кире кайтару” сүзләренә алмаштырырга;

9) 9 статьяда:

а) исемендә “аны йөртүченең керә алуы” сүзләрен “керә алу” сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә “транспорт чарасын йөртүче” сүзләрен “транспорт чарасы хуҗасы, аның вәкиле яисә тоткарланган транспорт чарасын йөртү өчен кирәкле документлары булган зат (алга таба – транспорт чарасы хуҗасы)” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлештә “Тоткарланган транспорт чарасына аны йөртүче” сүзләрен “Тоткарланган транспорт чарасына транспорт чарасы хуҗасы” сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлештә:

4 пунктта “транспорт чарасын йөртүченең” сүзләрен “транспорт чарасы хуҗасының” сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта “махсуслаштырылган урында” сүзләреннән соң “тоткарланган” сүзен өстәргә;

6 пунктта “транспорт чарасыннан аны йөртүче” сүзләрен “тоткарланган транспорт чарасыннан транспорт чарасының хуҗасы” сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә “аны йөртүче” сүзләрен “транспорт чарасының хуҗасы” сүзләренә алмаштырырга;

е) 5 өлештә “транспорт чарасын йөртүче” сүзләрен “транспорт чарасының хуҗасы” сүзләренә алмаштырырга, “махсуслаштырылган урында” сүзләреннән соң “тоткарланган” сүзен өстәргә, “транспорт чарасын йөртүчегә” сүзләрен “транспорт чарасы хуҗасына” сүзләренә алмаштырырга;

10) 10 статьяның 4 өлешендә “транспорт чарасын аны йөртүчегә биргәндә” сүзләрен “аны транспорт чарасы хуҗасына кире кайтарганда” сүзләренә алмаштырырга;

11) 11 статьяда:

а) 1 өлештә “хуҗасына биргән” сүзләрен “транспорт чарасы хуҗасына кире кайтарган” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә ике урында “бирү” сүзен ике урында “кире кайтару” сүзләренә алмаштырырга;

12) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“12 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү һәм аны саклау бәясен түләү**

1. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү (төяү-бушату эшләрен дә кертеп) һәм тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга урнаштырган вакыттан алып махсуслаштырылган урыннан кире кайтарган вакытка кадәр саклау бәясе түләнергә тиеш.

2. Транспорт чарасын тоткарлау сәбәбе аны махсуслаштырылган транспорт чарасына төягәннән соң һәм ул кузгалып киткәнче бетерелгән очракта, төяү-бушату эшләре бәясе түләнергә тиеш.

3. Тоткарланган транспорт чарасын күчерү һәм саклау бәясен махсуслаштырылган урында тәүлек әйләнәсенә түләү мөмкинлеге тәэмин ителә.

4. Тоткарланган транспорт чарасын саклау өчен махсуслаштырылган урынга урнаштыру факты булмаган очракта, транспорт чарасы хуҗасы төяү-бушату эшләре бәясен транспорт чарасын тоткарлау турында карарны үтәүче затка түләргә хокуклы.

5. Тоткарланган транспорт чарасын саклаган өчен түләү аның махсуслаштырылган урында торган һәр тулы сәгате өчен алына.

6. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчерү (төяү-бушату эшләрен дә кертеп) һәм аны саклау бәясен түләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы билгели торган срокларда һәм тарифлар буенча башкарыла.”;

13) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“13 статья. **Тоткарланган транспорт чарасын кире кайтару**

1. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан транспорт чарасының хуҗасына кире кайтару Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 27.13 статьясының 3 өлеше нигезендә транспорт чарасын тоткарлауны туктату турында карар кабул итәргә вәкаләтле вазыйфаи затның язмача рөхсәте нигезендә гамәлгә ашырыла. Вәкаләтле вазыйфаи затның рөхсәттәге имзасы тиешле эчке эшләр органының яисә кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе органының түгәрәк мөһере белән таныклана.

2. Транспорт чарасының хуҗасы, тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан кире кайтару турында мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклаучы документ, транспорт чарасына тиешле теркәү документларын һәм әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән язмача рөхсәтне күрсәтергә тиеш.

3. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан кире алганда, транспорт чарасының хуҗасы, тоткарланган транспорт чараларын саклау өчен җаваплы зат алдында үз транспорт чарасын карап-тикшереп чыга.

4. Тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан кире кайтару турында акт төзелә. Тоткарланган транспорт чарасын кире кайтару турындагы актта (алга таба – кире кайтару турында акт) түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан кире кайтарган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

2) транспорт чарасы хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләр, яшәү урыны, туган көне һәм урыны хакында белешмәләр;

3) әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, тоткарланган транспорт чарасын кире кайтару өчен нигез булып торган язмача рөхсәт турында белешмәләр;

4) тоткарланган транспорт чарасына карата күрсәтелгән теркәү документлары турында белешмәләр;

5) тоткарланган транспорт чарасы турында беркетмәдә күрсәтелгән белешмәләр;

6) тоткарланган транспорт чарасын мөһерләп бикләп куюю өчен кулланылган пломбалы ярлыклар номерлары, аларның бөтенлеге хакында белешмәләр;

7) тоткарланган транспорт чарасын махсуслаштырылган урыннан кире кайтару датасы һәм вакыты, махсуслаштырылган урынның исеме (булган очракта) һәм урнашкан урыны;

8) тоткарланган транспорт чарасын күчерү һәм саклау бәясен түләү бурычы йөкләнгән зат тоткарланган транспорт чарасын күчерү һәм саклау бәясен билгеләнгән срокларда түләүдән баш тарткан очракта, бу бурычны мәҗбүри түләттерү ихтималын һәм аның тискәре нәтиҗәләрен тоткарланган транспорт чарасы кире кайтарыла торган транспорт чарасы хуҗасына аңлату турында белешмәләр.

5. Күчергәндә һәм (яисә) саклаганда тоткарланган транспорт чарасының сакланышын тәэмин итүгә карата транспорт чарасы хуҗасының дәгъвалары

булмаган очракта, кире кайтару турында актка бу хакта тиешле тамга куела. Күчергәндә һәм (яисә) саклаганда үз транспорт чарасының сакланышын тәэмин итүгә карата транспорт чарасы хуҗасының дәгъвалары булган очракта, бу хакта транспорт чарасы хуҗасы кире кайтару турындагы актта күрсәтә. Кире кайтару турында актның күчермәсе транспорт чарасы хуҗасына тапшырыла.

6. Транспорт чарасын тоткарлау турында карарны башкару чорында (күчерү һәм саклау вакытында) тоткарланган транспорт чарасына зыян килмәү турында белешмәләр кире кайтару турында актта транспорт чарасы хуҗасының имзасы белән таныклана.

7. Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган урында саклау өчен җаваплы зат тоткарланган транспорт чарасын тиешле хәлдә (транспорт чарасын тоткарлау вакытына) кире кайтару турында беркетмәгә язып куя, транспорт чарасы хуҗасы имза сала.

8. Тоткарланган транспорт чарасын кире кайтару турында акт транспорт чарасы хуҗасы һәм махсуслаштырылган урынның вазыйфаи заты тарафыннан имзалана.";

14) 14 статьяда "бирү" сүзен "кире кайтару" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 12 декабре
№ 97-ТРЗ